РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

___________________ №__________

Опека һәм попечительлек өлкәсендә
дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең
административ регламентларын
раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Гаилә кодексы нигезендә, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”гы 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге административ регламентларны расларга:

1.1. Опекага алынган затларны,стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль учреждениеләргә җибәрү турында карарлар бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә );

1.2. Суд тәртибендә эшкә сәләтсез яки чикләнгән эшкә яраклы дип танылган балигъ булган затка опека һәм попечительлек билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә );

1.3. Опекага алынган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.4. Балигъ булган эшкә сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә опекунга торакны хосусыйлаштыру өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.5. Опекунга опекага алынган затның торагын наемга тапшырырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.6. Опекага алынган затларның милке белән килешүләр төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.7. Яшәү урынын алыштыруга бәйле рәвештә опекунга опекага алынган затны яшәү урыны буенча теркәү исәбеннән төшерү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.8. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.9. Опекунга яки попечительгә опекага алынган затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.10. Опекунга (попечительгә), тәрбиягә бала алган ата-аналарга бала (балаларны) караган өчен акча билгеләү һәм түләү буенча ,шулай ук опекуннарга һәм попечительләргә, тәрбиягә бала алган ата-аналарга үз вазыйфаларын бушлай башкарган өчен акча түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.11. Ятимнәр йортында яшәүче һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнарның гаиләләренә вакытлыча яшәргә күчерү мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.12. Балигъ булмаган зат исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.13. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка/кызлыкка алу мөмкинлеге булу турында бәяләмә бирү һәм уллыкка/кызлыкка алучыга кандидат буларак исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.14. Балигъ булмаган затның күчмә милкен тартып алу буенча килешүләр төзүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.15 Ундүрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.16. Ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга (түләүсез яисә түләүсез шартларда)опекага билгеләү ,яки опекун булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.17. Балигъ булмаган затны эмансипацияләү(азат итү) турында Карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (балигъ булмаган баланы тулысынча эшкә яраклы дип игълан итү) (кушымта итеп бирелә);

1.18. Балигъ булмаган затның күчемсез милкен тартып алу буенча килешүләр төзүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.19. Балигъ булмаган затлар катнашында кредит акчаларын кулланып торак сатып алуга һәм аны залогка (ипотекага) тапшыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә);

1.20. Законлы вәкилгә балигъ булмаган затның акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (кушымта итеп бирелә).

2. Түбәндәге карарны һәм пунктларны үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында “гы 2016 елның 12 августындагы 1019-п номерлы карарының 1.1 − 1.10. пунктлары;

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Законлы вәкилгә акча кертемен алуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында “гы 2018 елның 12 ноябрендәге 1645-п номерлы карары;

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында “ гы 2013 елның 6 маендагы 566-п номерлы карарының 1.10-1.19 пунктлары.

3. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга**.**

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге баш белгече З.Ф. Хисамиевага йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р. Ишниязов